КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 декабрь г.Казань № 1099

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасының Аксубай муниципаль районында «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен юридик затлар (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре) милкендә булган, 1 нче кушымтада күрсәтелгән, 14 545 456,18 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән барлыкка килә торган 98 388 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Җир кишәрлекләрендә урнашкан һәм 2 нче кушымтада күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектлары алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районындагы Кәкрекүл, Яңа Аксубай, Иске Үзи авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының «Планлаштыру проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2019 елның 25 июлендәге 487 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру һәм межалау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен башкаруны;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләү күләмен билгеләүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 5 декабрь, 1099 нчы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле
җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Җир кишәрлеге-нең гомуми мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 16:03:070701:1 | Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы | 7 244 | 1 216 | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте |
| 16:03:070701:14 | Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы | 11 431 | 251 | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте |
| 16:03:000000:26 | Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы | 149 927,18 | 26 618 | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте |
| 16:03:000000:26 | Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы | 149 927,18 | 177 | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте |
| 16:03:070602:211 | Татарстан Республикасы, Аксубай муници-паль районы, Кәкрекүл авыл җирлеге | 10 300 | 159 | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте |
| 16:03:000000:1868 | Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Иске Үзи авыл җирлеге | 8 186 824 | 67 729 | «Татагролизинг» акционерлык җәмгыяте |
| 16:03:000000:1873 | Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Яңа Аксубай авыл җирлеге | 6 179 730 | 2 238 | «Җәлил» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| Барлыгы | | 14 545 456,18 | 98 388 | |

______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 5 декабрь, 1099 нчы
карарына 2 нче кушымта

Җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге

| Т/с | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объекты исеме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | 16:03:070701:1 | 16:03:000000:1340 | «Нефть ятмалары корылмасы. Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү» |
| | | 16:03:000000:1780 | «Юл транспорты корылмалары. «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы» автомобиль юлы |
| | | 16:03:070701:285 | «ЦСП дан ДНС-1а га кадәр килә торган суйөрткеч» |
| | | 16:03:150101:1306 | «Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. «Азат» 4 нче ДНСны реконструкцияләү» |
| 2. | 16:03:070701:14 | 16:00:000000:880 | «ППН-Сервис» ҖЧҖнең «Азат» төркемле үлчәү насос җайланмаларыннан 1 нче нефть суыртып агызу станциясенә кадәр нефтьүткәргеч» |
| | | 16:03:000000:1313 | «Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү ВЛ-35 кВ» |
| | | 16:03:000000:1340 | «Нефть ятмалары корылмалары. Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү» |
| | | 16:03:000000:1780 | «Юл транспорты корылмалары. «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы» автомобиль юлы |
| | | 16:03:150101:1306 | «Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. «Азат» 4 нче ДНСны реконструкцияләү» |
| 3. | 16:03:000000:26 | 16:03:000000:1498 | «Килү юлы» |
| | | 16:03:000000:1780 | «Юл транспорты корылмалары. «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы» автомобиль юлы |
| | | 16:03:060601:761 | «Нефть ятмалары корылмалары. Пионер нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү» |
| | | 16:03:070602:244 | «Нефть ятмалары корылмалары. ПЗ-2889дан ГЗУ-305кә кадәр ДУ 159 нефть-газ җыю |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | торбаүткәргече» |
| | | 16:03:150101:1554 | «Нурлатнефть» нетфь-газ чыгару идарәсенең «Пионер» төркемле үлчәү насос җайланмасы узелын газ белән тәэмин итү» |
| | | 16:03:000000:2250 | «Электр энергетикасы корылмалары. Аксубай-Мукшы нефть ятмаларын төзекләндерү. 35 кВ һава линиясеннән 220 нче ярдәмче станция» |
| | | 16:03:060601:1153 | «Нефть ятмалары корылмалары. Пионер нефть ятмасын төзекләндерү (3 нче чират)» |
| 4. | 16:03:070602:211 | 16:03:000000:1340 | «Нефть ятмалары корылмалары. Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү» |
| | | 16:03:000000:1780 | «Юл транспорты корылмалары. «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы» автомобиль юлы |
| 5. | 16:03:000000:1868 | 16:03:000000:1779 | «Юл транспорты корылмалары. «Аксубай – Федоровка» – Ерепкино – Святой Ключ» автомобиль юлы |
| | | 16:03:000000:1780 | «Юл транспорты корылмалары. «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы» автомобиль юлы |
| | | 16:03:070602:243 | «Нефть ятмалары корылмалары. ПЗ-2892дән ГЗУ-323кә кадәр ДУ 159 нефть-газ җыю торбаүткәргече» |
| | | 16:03:070602:244 | «Нефть ятмалары корылмалары. ПЗ-2889дән ГЗУ-305кә кадәр ДУ 159 нефть-газ җыю торбаүткәргече» |
| | | 16:03:000000:2250 | «Электр энергетикасы корылмалары. Аксубай-Мукшы нефть ятмаларын төзекләндерү. 35 кВ һава линиясеннән 220 нче ярдәмче станция» |
| 6. | 16:03:000000:1873 | 16:00:000000:880 | «ППН-Сервис» ҖЧҖнең «Азат» төркемле үлчәү насос җайланмаларыннан 1 нче нефть суыртып агызу станциясенә кадәр нефтьүткәргеч» |
| | | 16:03:000000:1310 | «БГ-1 дән алып 2812 нче скважинага кадәр югары этемле суйөрткеч. Ду = 89 х 7 МПТК» |
| | | 16:03:000000:1313 | Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү. 35 кВ һава линиясе» |
| | | 16:03:000000:1645 | «Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү (1 нче чират)» проект документациясе нигезендә «Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының нефть җыю системасын реконструкцияләү (1 нче чират)» |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | 16:03:000000:1780 | «Юл транспорты корылмалары. «Аксубай – Федоровка» – Яңа Баланда – Яңа Мукшы» автомобиль юлы |
| | | 16:03:000000:1781 | «Юл транспорты корылмасы. «Аксубай – Федоровка» – Кече Аксубай» автомобиль юлы |
| | | 16:03:000000:1843 | «Юл транспорты корылмасы. «Аксубай – Федоровка» – Федоровский» автомобиль юлы |
| | | 16:03:070701:312 | «2815 нче скважинадан БГ-2804 кә кадәр чыгарма торба үткәргеч. ДУ = 89 х 4 ТПСУ» |
| | | 16:03:000000:2198 | «Газ-химия комплексы корылмалары. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Д 110 мм югары басымлы газүткәргечтән Аксубай урман заводына кадәр тармакландыру» |
| | | 16:03:000000:2282 | «Газопровод в/д» торба үткәргеч транспорты корылмалары |
| | | 16:03:000000:2348 | «Суүткәргеч» |
| | | 16:03:000000:2347 | «Суүткәргеч» |
| | | 16:03:150101:1306 | «Аксубай-Мукшы нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. «Азат» 4 нче ДНСны реконструкцияләү» |

______________________________